ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«24» октябрь 2022 ел №955

**2023 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга сәнгати-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында**

«Татарстан Республикасының балаларга сәнгати-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү учреждениеләренә финанслау нормативларын кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары һәм Арча муниципаль районы Уставы нигезендә Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга түбәндәгеләрне кушымта нигезендә расларга:

2023 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга сәнгати-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга сәнгати-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата төзәтмә коэффициены 0,65 күләмендә.

2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МКУнә әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирүче оешмаларны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э.Ш.Вафинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р. М. Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
24.10. 2022 ел, № 955
карары белән расланды

**2023 елга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының өстәмә белем бирү оешмаларында балаларга сәнгати-эстетик юнәлештә өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территория ягыннан урнашуы | Нормативы чыгымнар (бер укучыга елына сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку срогы | дүрт еллык уку срогы | биш еллык уку срогы | җиде еллык уку срогы | иртә һөнәри юнәлеш |
| Музыка сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 74 988 | 85 669 | 110 026 |
| Музыка сәнгате | авыл җирлеге | | | 79 714 | 91 055 | 116 878 |
| Нәфис сәнгать | шәһәр җирлеге | | 39 699 | | 35 247 | 84 588 |
| Нәфис сәнгать | авыл җирлеге | | 42 126 | | 37 425 | 89 801 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 83 632 | 68 869 | 252 446 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 88 953 | 73 250 | 268 494 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 35 168 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 37 395 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 76 896 | 73 832 | 118 624 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 81 803 | 78 547 | 126 162 |
| Эстрада-джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 115 796 | | 111 004 | | 182 027 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 123 091 | | 118 014 | | 193 471 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 59 697 | | 55 573 | 55 492 | 83 712 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 63 434 | | 59 063 | 58 977 | 88 859 |